Биектау муниципаль районы Өнсә авылы “Гүзәл” балалар бакчасы

# *Тема:*

# «Балаларны дәүләт телләренә өйрәтү»

***Гиниятуллина Римма Фоат кызы***
***тәрбияче, 1 кв. категория, пед.стаж -22 ел***

FUTURU.RU




Республикабызда хәзер татар теле һәм рус телләре тигез хокуклы дәүләт телләре булып санала. Әхмәт Ерикәйнең күп еллар элек язылган бу шигыре бүген дә актуаль яңгырый:

Заман миңа: «Югарыга мен!» — дип,
Ике канат биреп үстерде.
Канатымның берсе — татар теле,
Икенчесе — бөек рус теле!..

Белүебезчә, билингвизм - ике телдә иркен аралаша алу, ситуациягә карап, бу телләрне кирәк чакта куллана белү.


Изучаем русский язык
Туган телдә





Ата- аналарны ,үзебезнең эшкә җәлеп итү өчен балаларны дәүләт телләренә өйрәтү чаралары, алымнары, татар халык бәйрәмнәре, татар язучыларының юбилейларына багышланган материаллар, гомумән, мәгариф өлкәсендәге яңалыклар белән таныштыру өчен информацион-күрсәтмә материаллар булдырдык.

tkornienko


Туган телдә сөйләшәбез
"Өстәл театры" - атрибутлары





Бүген мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләрендә эшләүче тәрбиячеләр алдында торган бурычларның иң мөһиме – балаларга ике телне өйрәтү, аларны халкыбызның тарихы, матур йола, гореф-гадәтләре, милли бәйрәмнәре, мәдәнияте белән таныштыру. Бу эшне төрле методик алымнар белән оештырырга мөмкин:

балалар белән сөйләшү;

аерым темага әңгәмәләр үткәрү;

тәрбияченең сәнгатьле итеп укуы һәм әдәби телдә сөйләве;

балаларның үзләреннән сөйләтү;

дидактик уеннар уйнау;

тизәйткечләр, санамышлар, табышмаклар, халык мәкальләреннән файдалану һәм башкалар.

tkornienko





Бакчабызда “Халыкара туган тел көне”, “Нәүрүз” бәйрәме, “Тукай безнең йөрәкләрдә”, “М.Җәлил-герой шагыйрь” бәйрәмнәре булып узды. Балаларга һәм әти-әниләргә мондый чаралар, бәйрәмнәр бик ошый. Чөнки балалар төрле яклап ачылалар, үзләренең осталыкларын, сәләтләрен, тел белүләрен күрсәтәләр.

tkornienko



FISHING




Белем бирү эшчәнлекләренең темасы баланың сөйләм телен камилләштерү максатын күздә тотып төзелгән. Аудиоматериал һәм мультипликацион сюжетлар һәр эшчәнлектә дә кулланмый. Кулланылган очракта да эшчәнлекнең бер өлеше булып бара. Шулай ук эшчәнлектә без төрле уеннар уйныйбыз. ”Бармак уеннары”, “Шалкан әкияте” театры, “Яшелчә”, “Кием”, “Савыт-саба”, “Уенчык” кибете уеннары, битлекләр белән уеннар. Эшчәнлектәге өйрәнгән сүзләрне тагын да ныграк ныгыту, балаларны кызыксындыру өчен үзебез ясаган дидактик уеннар кулланабыз. Эшебездә балалар белән җырлы-биюле уеннарны да бик яратып кулланабыз. М-н: “Бар матур бакча”, “Бу өй матур, бу өй зур”, “Төсле туп” һ.б.












# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!